Республика Татарстан
Главы Александро-Слободского
сельского поселения Заинского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Александр Бистәсе авыл
җирлеге башлыгы

Ул. Центральная, д. 73 с. Ал. Слобода,
Заинский район, 423503

Үзәк урамы, 73 нче йорт,
Ал.Слобода авылы, Зәй районы,
423503

Телефон, факс 6-27-30. Электронный адрес: Aslob.Zai@tatar.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 4**

**КАРАР**
**«21» августа 2023г.**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге башлыгының «Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны оештыру тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2011 елның 10 августындагы 1номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон, Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге уставына таянып,

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгының 2011 елның 10 августындагы 1 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны оештыру тәртибе хакында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктына «һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләрен өстәргә;

1.2. 5.1 пунктның 4 пунктчасында «җирле үзидарә органнары, аларның вазыйфаи затлары» сүзләрен «җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар, күрсәтелгән органнарның һәм оешмаларның вазыйфаи затлары» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Подпункт 4 пункта 6.1 после слов «Исполнительным комитетом Поселения» дополнить словами «и подведомственными организациями»;

1.4. 6.1 пунктның 4 пунктчасына «Җирләүнең башкарма комитеты» сүзләреннән соң «һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләрен өстәргә;

1.5. 9.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9.6. Җирле үзидарә органнарының һәм аның карамагындагы оешмаларның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, ведомство буйсынуындагы оешмаларның җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану хокукын бозуда гаепле хезмәткәрләре Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар, административ, гражданлык һәм җинаять җаваплылыгына тартыла».

2. Әлеге карарны җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Александр Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Л.Г.Варганова